2СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

08.11.2024 ел Баулы шәһәре № 273

Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына (Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 176 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 274 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 90 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 138 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 151 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 257 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктының 3 абзацында «13 323» цифраларын «13 990» цифралары белән алмаштырырга;

әлеге карарга 2-нче номерлы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә  (бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Баулы муниципаль район
Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Хәмидуллин

Баулы муниципаль район Советының
2018 елның 20 апрелендәге
149 номерлы карарына
2-нче номерлы
Кушымта

(Баулы муниципаль район
Советының 2024 елның
8 ноябрендәге 273 номерлы
карары редакциясендә)

Муниципаль район Башлыгының, Муниципаль район Башлыгы урынбасарының, муниципаль районның контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 4 группа |
| Муниципаль район Башлыгы | 38 889 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 34 998 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 34 998 |